БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
17 декабрь 2018 ел № 159

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2018 елга, 2019-2020 еллар план чорына бюджеты турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 20.12.2017 елгы 104 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» гы Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 1 ноябрендә кабул ителгән 143 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләм, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2018 елга, 2019-2020 еллар план чорына бюджеты турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 20.12.2017 елгы 104 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» гы Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 1 ноябрендә кабул ителгән 143 номерлы карарының 1 пунктнын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2018 елга, 2019-2020 еллар план чорына бюджеты турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 20.12.2017 елгы 104 номерлы карарына (28.04.2018, 26.07.2018 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2018 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 877538,16 мең сум;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 914505,47 мең сум;

3) Балтач муниципаль районы бюджеты дефициты 36967,31 мең сум.».

1.2. Карарның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны исәпкә алырга: